**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**

**Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы.**

**КАРАР**

№ 66 2 .10. 2018 ел

**Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, 2004 елның 24 мартындагы 18 статьясына ярашлы № 23-ЗРТ «җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы белән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 18.09.2018 ел, №65 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябрендә якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?":

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

1) Иске Кыязлы торак пунктында Яшьләр, Яңа, М.Җәлил, Ленин урамнары буенча вак таш белән капланган юлларны ремонтлау.

2) Иванов, Чапаев, Николаев урамнары буенча Яңа Кыязлы торак пунктына юллар салу.

3) юлларны кышкы тоту;

2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

1) су күтәрү манарасын урнаштыру һәм Кызыл Тау торак пунктындагы манарага кадәр суүткәргеч салу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

2) Иске Кыязлы авылында су күтәрү манарасы өчен тирәнлек насосы сатып алу.

3. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

1) Янгын сүндерү машинасын тоту һәм шоферга түләү.

ӘЙЕ ЮК

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум округын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Кыязлы авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге участок сайлау комиссиясе гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында да.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: Г. Г. Дәүләтшин